Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Уракчы авыл җирлеге Советы

**КАРАР № 3**

Уракчы авылы 7 декабрь, 2021 ел

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уракчы авыл җирлеге Советының 2014 елның 07 октябрендәге “Җир салымы турында”гы 14 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль норматив хокукый актны гамәлдәге законнарга туры китерүмаксатларында, 2021 елның 7 июлендәге “Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешенә һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында”305-ФЗ номерлы Федераль закон,Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының“Уракчы авылҗирлеге”муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уракчы авыл җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уракчы авыл җирлеге Советының 2014 елның 07 октябрендәге “Җир салымы турында”гы 14 номерлы карарына Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уракчы авыл җирлеге Советының 2014 елның 11 ноябрендәге 15 номерлы, 2015 елның 28 маендагы 11 номерлы, 2017 елның 22 августындагы 11 номерлы, 2019 елның 14 июнедәге 10 номерлы, 2020 елның 2 февралендәге 2 номерлы карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән ) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктның 2 абзацында “, шулай ук күрсәтелгән объектларны урнаштыру өчен аталган җир кишәрлекләре” сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карар рәсми игълан ителгән (халыкка җиткерелгән) көненнән үз көченә керә һәм 2021 елның салым чорындагы җир салымын исәпләүгә бәйле хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уракчы авыл җирлегенең Уракчы авылы, Совет ур., 36А йорт; Мельничный Пүчинкәсе авылы, Киров ур., 20 Б адреслары буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

4. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Уракчы авыл җирлеге башлыгы Ф.М.Гараев